Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел № 5

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Иске Суркино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Ўставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 15 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Иске Суркино авылының Урман асты, Мәктәп, Үзәк урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Иске Суркино авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Үзәк урамы, 77А йорты.

2. 2019 елның 16 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Иске Суркино авылының Октябрь, Елга арты, Яшьләр урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Елга арты урамы, 10А йорты.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлегенең Иске Суркино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: территорияне төзекләндерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?”

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Иске Суркино авылында сайлау хокукына ия авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Иске Суркино, Үзәк урамы, 77 йорт  территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Иске Суркино
авыл җирлеге башлыгы Н.В. Леонтьев